Республика Татарстан
Руководитель Исполнительного комитета Чубуклинского сельского поселения Заинского муниципального района

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Чыбыклы авыл җирлегенең
башкарма комитеты
җитәкчесе

ул. Молодежная, д. 229/В, с. Чубуклы,
Заинский район, 423534

Яшьләр урамы, 229/В нче, Чыбыклы
авылы, Зәй районы, 423534

Телефон, факс 3-68-01. Электронный адрес: Chub.zai@tatar.ru, сайт: www.chubuklinskoe.jimdo.com

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**17.11. 2021г.** **№ 13**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм аны гамәлгә ашыру турында» нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Конституциясе, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Хәрби исәпкә алу турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, "Хәрби исәпкә алу турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында" 2020 елның 06 февралендәге 103 номерлы карарларга нигезләнеп, Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм аны гамәлгә ашыру турында» нигезләмәне расларга (1 нче кушымта нигезендә).
2. Беренчел хәрби исәпкә алуны алып баручы хезмәткәрнең вазифаи инструкциясен расларга (2 нче кушымта нигезендә).
3. Запастагы гражданнарны һәм армиягә чакырылырга тиешле гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны алып бару йөкләмәләрен Чыбыклы авыл җирлеге башкарма комитетының беренчел хәрби исәп эшен алып баручы белгеченә йөкләргә.
4. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 26.07 8 номерлы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип таныргa.

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.
6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Н. Гадершин**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районының
Чыбыклы авыл җирлеге
башкарма комитетының
2021 елның 17.11
13 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында»

# НИГЕЗЛӘМӘ

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Беренчел хәрби исәпкә алу Чыбыклы авыл җирлегенең хәрбиләрне исәпкә алу буенча хезмәткәре тарафыннан башкарыла.

1.2. Хәрби исәпкә алу хезмәткәре үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, "Оборона турында" 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль законга, "Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында" 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль законга (2004 елның 22 августындагы 122 номерлы закон нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән), "Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында" 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 октябрендәге 719 номерлы карары белән расланган хәрби исәпкә алу турында нигезләмәгә, "Вәкаләтләрне бүлешүне камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2005 елның 31 декабрендәге 199-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре запастагы Россия Федерациясе гражданнарын, запастагы федераль башкарма хакимият органнарында һәм дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм оешмаларда эшләүче Россия Федерациясе гражданнарын хәрби вакытта һәм мобилизацияләү чорына броньлау буенча инструкциягә, Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге Уставына, шулай ук әлеге нигезләмәгә таяна.

1.3. Нигезләмә Чыбыклы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Хәрби исәп хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләү, күчерү һәм эштән азат итү муниципаль берәмлекнең хәрби комиссары белән килешенеп башкарыла.

## II. ТӨП БУРЫЧЛАР

2.1. Хәрби исәпкә алу буенча хезмәткәрнең төп бурычлары булып тора:

гражданнарның "Оборона турында", "Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында", "Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында" федераль законнарда билгеләнгән хәрби бурычны үтәвен тәэмин итү;

хәрби исәптә торучы гражданнар турында хәрби исәпкә алу белешмәләрен документаль рәсмиләштерү;

ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү мәнфәгатьләрендә нәтиҗәле файдалану өчен хәрби мобилизация ресурсларының сан составын һәм сыйфатын анализлау;

Россия Федерациясе Кораллы көчләрен, башка гаскәрләрне, хәрби формированиеләрне һәм органнарны тыныч тормыштан сугыш вакытына мобилизацияләү чорында һәм аларның комплектлануын хәрби вакытта таләп ителгән дәрәҗәдә тоту өчен запастагы, хәрби әзерлекле гражданнарның кирәкле санын әзерләү буенча планлы эш алып бару.

## III. ФУНКЦИЯЛӘР

3.1. Көндәлек эшчәнлектә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алу һәм броньлау буенча администрациягә йөкләнгән функцияләрне башкаруны җирле үзидарә органы администрациясендә эшләүчеләрдән тәэмин итә.
3.2.. Җирлек территориясендә запаста торучы гражданнарны һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарны, шул исәптән яшәү урыны һәм (яисә) килү урыны буенча (3 айдан артык вакытка) теркәлүе булмаган гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны башкара.
3.3. Җирлек территориясендә яшәүче яисә килүче (3 айдан артык вакытка), шул исәптән яшәү урыны һәм (яисә) килү урыны буенча теркәлмәгән һәм хәрби исәпкә куелырга тиешле гражданнарны эчке эшләр органнары белән берлектә ачыклау.
3.4. Җирле үзидарә органнары үз эшчәнлеген алып бара торган территориядәге оешмаларның исәбен алып барырга һәм аларда хәрби исәп алып баруны контрольдә тотарга.
3.5. Елына кимендә бер тапкыр беренчел хәрби исәпкә алу документларын муниципаль берәмлек хәрби комиссариатының, оешмаларның хәрби исәпкә алу документлары белән, шулай ук теркәлү карточкалары яки йорт китаплары белән чагыштырырга.
3.6. Муниципаль берәмлек хәрби комиссариаты күрсәтмәсе буенча гражданнарга хәрби комиссариатка чакырулар турында хәбәр итү.
3.7. Беренчел хәрби исәпкә алу документларындагы белешмәләргә үз вакытында үзгәрешләр кертергә һәм муниципаль берәмлекнең хәрби комиссариатына кертелгән үзгәрешләр турында ике атна эчендә хәбәр итәргә.
3.8. Ел саен 1 октябрьгә кадәр хәрби комиссариатка 15 яшькә җиткән ир-ат гражданнар һәм 16 яшькә җиткән ир-ат гражданнар исемлекләрен, ә 1 ноябрьгә кадәр киләсе елда хәрби исәпкә куелырга тиешле гражданнарның исемлекләрен хәрби исәпкә алу турында Положениедә билгеләнгән форма буенча тәкъдим итәргә.
3.9. Оешмаларның вазыйфаи затларына һәм гражданнарга Россия Федерациясе законнарында һәм хәрби исәпкә алу турында нигезләмәдә билгеләнгән хәрби исәпкә алу, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация буенча бурычларны аңлатырга һәм аларның үтәлешен контрольдә тотарга.

## IV. ХОКУКЛАР

4.1. Планлы һәм максатчан эш алып бару өчен хәрби исәпкә алу хезмәткәре хокуклы:
дәүләт хакимиятенең федераль органнарыннан, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә учреждениеләрдән һәм оешмалардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материаллар һәм мәгълүмат алу буенча тәкъдимнәр кертергә;

җирле үзидарә органы администрациясенең структур бүлекчәләреннән аналитик материаллар, чараларның җыелма планнары буенча тәкъдимнәр һәм аларны үтәү турында мәгълүмат, шулай ук йөкләнгән бурычларны нәтиҗәле үтәү өчен кирәкле башка материалларны соратырга һәм алырга;
үз компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча мәгълүмат базасы төзергә;
җирле үзидарә органы җитәкчесе тарфыннан карауга аерым эшләрне башкару өчен хезмәткәрләрне шартнамә нигезендә җәлеп итү турында мәсьәләләрне чыгарырга;
билгеләнгән тәртиптә үзара хезмәттәшлекне оештырырга һәм федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук үз компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча оешмалар белән хезмәт язышуын тәэмин итәргә.

## V. ҖИТӘКЧЕЛЕК

5.1. Хәрби исәпкә алу хезмәткәре Чыбыклы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан билгеләнә һәм вазыйфасыннан азат ителә һәм ул берьюлы ике эшне алып бара.
5.2. Хәрби исәпкә алу хезмәткәре Чыбыклы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә турыдын-туры буйсына.
5.3. Хәрби исәпкә алу буенча хезмәткәр җитди сәбәпләр белән (чираттагы ял, вакытлыча хезмәткә яраксызлык, эш сәфәре) эш урынында булмаган очракта, аны Поручик авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе алыштыра.

**Чыбыклы авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **И.Н. Гадершин**

**Чыбыклы авыл җирлегенең**
**беренчел хәрби исәпкә алу буенча белгече** **Е.А. Егорова**

«КИЛЕШТЕРЕЛДЕ»

Татарстан Республикасы
Зәй шәһәре һәм Зәй районы
хәрби комиссары

______________ А. Ф. Әгъләмҗанов

______________
(дата)

«РАСЛЫЙМ»

ТР Зәй муниципаль районының
Чыбыклы авыл
җирлеге җитәкчесе

______________ И.Н. Гадершин

______________
(дата)

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районының
Чыбыклы авыл җирлеге
башкарма комитетының
2021 елның 17.11
13 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алу һәм броньлау, запастагы гражданнарны исәпкә алу буенча хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясе**

Беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары "Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында" Федераль законга таянып үз вазыйфаларын башкара.

Беренчел хәрби исәпкә алу документларында булырга тиешле белешмәләрне җыюны, саклауны һәм эшкәртүне оештыру һәм тәэмин итү максатларында җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары:
- җирлек территориясендә яшәүче яки булучы (3 айдан артык вакыт) запастагы гражданнарны һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарны, шул исәптән яшәү урыны һәм (яисә) килү урыны буенча (3 айдан артык вакытка) теркәлүе булмаган гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны башкаралар;
- үз территорияләрендәге оешмаларның исәбен алып баралар һәм Методик рекомендацияләргә 13 нче кушымта нигезендә аларда хәрби исәпкә алу эшен алып баруны тикшереп торалар;
- Методик рекомендацияләргә 14 нче кушымта нигезендә тәртиптә һәм форма буенча машинкада язылган һәм электрон рәвештә беренчел хәрби исәпкә алу документларын алып баралар һәм саклыйлар.
Беренчел хәрби исәпкә алу документларындагы мәгълүматларны актуаль халәттә тоту һәм хәрби исәпкә алу документларындагы белешмәләрне актуаль халәттә саклауны тәэмин итү максатларында җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары:
- елына кимендә бер тапкыр беренчел хәрби исәпкә алу документларын муниципаль берәмлек хәрби комиссариатының, оешмаларның хәрби исәпкә алу

документлары белән, шулай ук теркәлү карточкалары яки йорт китаплары белән Методик рекомендацияләргә 15 нче кушымта нигезендә чагыштыралар;
- Методик рекомендацияләргә 16 нчы кушымта нигезендә беренчел хәрби исәпкә алу документларындагы белешмәләргә үз вакытында үзгәрешләр кертәләр һәм муниципаль берәмлекнең хәрби комиссариатына кертелгән үзгәрешләр турында ике атна эчендә хәбәр итәләр;
- Методик рекомендацияләргә 17 нче кушымта нигезендә оешмаларның вазыйфаи затларына һәм гражданнарга Россия Федерациясе законнарында һәм хәрби исәпкә алу турында нигезләмәдә билгеләнгән хәрби исәпкә алу, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация буенча бурычларны аңлаталар һәм аларның үтәлешен контрольдә тоталар, шулай ук күрсәтелгән бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылык турында мәгълүмат бирәләр;
- Методик рекомендацияләргә 18 нче кушымта нигезендә хәрби комиссариатларга оешмаларның вазыйфаи затлары һәм гражданнарның хәрби исәпкә алу, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация буенча бурычларын үтәмәгән очраклар турында белешмәләр бирәләр.
Булуын һәм дөреслеген тикшерәләр:
- Хәрби билетларның (запастагы офицерларның хәрби билетлары Россия Федерациясе гербы сурәтләнгән һәм "Россия Федерациясе. Запастагы офицерның хәрби билеты" дигән язулы хәрби тышлыкка ия, 2000 елга кадәр чыгарылган хәрби билетларның тышлыгында СССР гербы һәм Оборона министрлыгы язулары сурәтләнгән. СССР Кораллы Көчләре запасы офицерының хәрби билеты яки СССР Кораллы Көчләре запасы генералының хәрби билеты" дип язылган); сурәтләнгән.
- солдат (матрос) сержантларның (старшиналар), прапорщикларның (мичманнар) хәрби билетларын (кызыл тышлы Россия Федерациясе Гербы сурәтләнгән һәм "Россия Федерациясе Хәрби билет" дип язылган (1994 елга кадәр чыгарылган хәрби билетларның тышлыгында СССР гербы һәм "СССР Хәрби билеты Оборона министрлыгы"дигән язылган);
- хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлыча таныклыкларны (бары тик хәрби билетларны рәсмиләштерү һәм бирү өчен тиешле документлары булмаган аерым хәрби бурычлыларның шәхесен билгеләү максатларында гына бирелә, кирәк булганда алар тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген раслау өчен, шулай ук элекке яшәү урыны буенча вакытлыча комиссариатка тапшырган хәрби билетларны сорату һәм алу өчен, ул хәрби комиссар тарафыннан имзалана һәм герблы мөһер белән таныклана. Гражданнарга вакытлыча таныклыклар бер айга бирелә. Хәрби комиссарлар хәрби билет урынына бирелгән вакытлы таныклыкларның гамәлдә булу вакытын 1 айга кадәр озайта алалар, ләкин тиешле документлар яки бер ай эчендә хәрби билет бирү өчен кирәкле белешмәләр килеп җитмәгәндә, гомуми вакыт 3 айдан да артмаска тиеш);
хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның таныклыкларын (хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле граждан таныклыгы Россия Федерациясе гербы һәм "Россия Федерациясе" язуы төшерелгән тышлыкка ия), шулай ук алардагы язмаларның дөреслеген, мобилизацион күрсәтмәләр булуын (запастагы хәрби бурычлылар өчен хәрби билетларда аларны тапшыру турында билге булганда), Методик рекомендацияләргә 19 нчы кушымта нигезендә, гражданнарны хәрби исәпкә алу документларында элекке яшәү урыны буенча хәрби исәптән төшерү

турында билгене, Россия Федерациясе гражданнары паспортларында аларның хәрби бурычка мөнәсәбәтләре турында билгеләрне, Россия Федерациясе Кораллы көчләренең шәхси номерлары белән жетоннарны (запастагы хәрби бурычлылар өчен хәрби билетларында аларны тапшыру турында билге булганда).

Хәрби билетларның (хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлы таныклыкларның) һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнар таныклыкларының гражданның паспорт белешмәләренә, фотосурәтләр булуга, аның нәсценеке белән тәңгәллегенә, моннан тыш гамәлдә булу вакытын тикшерәләр.

Гражданнарны элекке яшәү урыны буенча хәрби исәптән төшерү һәм запастагы офицерларны һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарны яңа яшәү урыны буенча хәрби комиссариатта хәрби исәпкә кую турында билгеләр булуны тикшерәләр:

- запастагы офицерның хәрби билетында "Хәрби исәпкә алу һәм хәрби исәптән төшерү турында билге" 24 пунктында (31-33 битләр) хәрби комиссар яки өченче бүлек башлыгы имзасы һәм хәрби комиссариатның герблы мөһере белән расланган (запастагы офицерларны хәрби исәптән төшерү яисә запастагы офицерларны хәрби исәпкә кую өчен мөһер белән);

- хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле граждан таныклыгында "1. Хәрби исәпкә алу һәм хәрби исәптән төшерү" бүлегендә хәрби комиссариат штампы:

- хәрби бурычлының хәрби билетында (хәрби билетка алмашка бирелгән вакытлыча таныклыкта) - "Төшерелде" графасында хәрби комиссариат яки җирле үзидарә органы штампы.

Хәрби исәпкә кую турында билге булмаган очракта запастагы офицерларны һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарны яшәү урыны буенча хәрби комиссариатка җибәрәләр.

Хәрби билетларда (хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлы таныклыкларда) һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның таныклыкларында килешмәгән төзәтмәләр, төгәлсезлекләр һәм ялган документлар табылганда, битләр саны тулы булмаганда бу хакта тиешле чара күрү өчен хәрби комиссариатка хәбәр итәләр.

Гражданнардан хәрби билетны (хәрби билет урынына бирелгән вакытлыча таныклык) яки хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле граждан таныклыкны кабул итеп алганда документ хуҗасына Методик рекомендацияләргә 20 нче кушымта нигезендә расписка бирергә.

Запастагы офицерларга беренчел исәпкә алу карточкасын методик рекомендацияләрдә билгеләнгән тәртиптә тутыралар.

Прапорщиклар, мичманнар, старшиналар, сержантлар, солдатлар һәм матросларга (ике нөсхәдә) алфавит карточкасын һәм исәпкә алу карточкасын методик рекомендацияләрдә билгеләнгән тәртиптә тутыралар. Хәрби хезмәткә чакырылучыларның исәпкә алу карталарын әлеге Методик рекомендацияләр белән билгеләнгән тәртиптә тутыралар. Күрсәтелгән документларны тутыру хәрби билетлардагы (хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлы таныклыкларда) һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның таныклыкларындагы язмалар нигезендә башкарыла.

Шул ук вакытта хәрби исәпкә куелучы гражданнарның гаилә хәле, белеме, эш урыны, вазыйфасы, яшәү урыны яки вакытлыча тору урыны турында мәгълүматлар, документлардагы башка кирәкле белешмәләр төгәлләштерелә.

Хәрби исәпкә алганнан соң граждан документларында дөрес булмаган язмалар табылган очракта, гражданнарны хәрби билетларга (хәрби билетларга алмашка бирелгән вакытлы таныклыклар) һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның таныклыкларына тиешле үзгәрешләр кертү өчен җибәрәләр. Район, шәһәр яки муниципаль берәмлек чикләрендә яшәү урынын үзгәрткән гражданнарга, шулай ук хәрби билетларга алмашка бирелгән вакытлы таныклыклар белән килгән гражданнарга да, исемле исемлекне тутыралар һәм муниципаль берәмлекнең хәрби комиссариатына җибәрәләр һәм алар, фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, яшәү һәм эш урынын, билән торган вазыйфаны, элек хәрби исәптә торган җирле үзидарә органының исемен күрсәтеп (Методик рекомендацияләргә 21 кушымта нигезендә), хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнар исемлегенә кертелә. Бу гражданнар өчен хисап карталары һәм алфавит карточкалары тутырылмый.

Гражданны хәрби исәпкә кую турында солдат (матрослар), сержант (старшиналар), прапорщикларның (мичманнар) хәрби билетында һәм теркәлү карточкасында яки кенәгәдә - җирле үзидарә органы администрациясе штампы белән (запастагы солдат (матрос), сержант (старшина), прапорщикның (мичман) хәрби билетында – "Хәрби исәпкә алу һәм хәрби исәптән төшерү турында билгеләр" IX бүлегенең "Кабул ителде" графасында) билге ясала.

Мобилизация күрсәтмәсе белән башка районнардан (шәһәрләрдән) яки башка муниципаль берәмлектән килгән хәрби бурычлылар турында аларның элек хәрби исәптә торган урыннары хакында хәрби комиссариатка хәбәр итәләр.

Мобилизация күрсәтмәсен алу бары тик җирле үзидарә органы урнашкан территориядәге хәрби комиссариат күрсәтмәсе буенча гына башкарыла, бу хакта хәрби билетта тамга ясала:

- запастагы офицерның хәрби билетында - "Мобилизация күрсәтмәләрен бирү һәм алу турында билгеләр" 17 пунктының “Алынды” графасында (15-22 битләр);
- солдатларның (матросларның), сержантларның (старшиналарның), прапорщикларның (мичманнарның) хәрби билетында - "Мобилизация күрсәтмәләрен бирү һәм алу турында билгеләмәләр" VII бүлегенең “Алынды” графасында (16-18 битләр) - җирле үзидарә органы администрациясе штампы белән.

Запастагы офицерларны беренчел исәпкә алу карточкалары, запастагы солдатларның (матросларның), сержантларның (старшиналарның), прапорщикларның (мичманнарның) алфавит, исәпкә алу карточкалары, хезмәткә чакырылучыларның исәпкә алу карточкалары исәпкә алу карточкаларының тиешле бүлекләренә урнаштыралар.

Хәрби билетларны (хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлы таныклыклар), прапорщикларның, мичманнарның, старшиналарның, сержантларның, запастагы солдатларның һәм матросларның алфавит һәм исәпкә алу карточкаларын, мобилизацион күрсәтмәләрне, хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алу карталарын, хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның таныклыкларын һәм исемлекләрен, исәп карталарын, шулай ук хәрби бурычка карата граждан мөнәсәбәте турында билге булмаган Россия Федерациясе гражданнарының паспортларын хәрби комиссариатка хәрби исәпкә куюны рәсмиләштерү өчен ике атна эчендә тапшыралар. Хәрби хезмәткә чакырылучыларга хәрби исәпкә кую өчен тиешле хәрби комиссариатка шәхси килү

кирәклеге турында хәбәр итәләр. Моннан тыш, хәрби комиссариатларга хәрби исәпкә алу документларында һәм күрсәтмәләрдә төгәлсезлекләр, ялган документлар һәм битләр саны тулмау турында хәбәр итәләр. Гражданнарны хәрби исәпкә алу документлары нигезендә хәрби исәпкә кую мөмкин булмаган очракта, җирле үзидарә органнары гражданнарга хәрби комиссариатка шәхси килү кирәклеге турында хәбәр итәләр. Гражданнардан хәрби исәпкә алу документларын кабул итеп алганда расписка бирелә.

Методик рекомендацияләргә 22 кушымта нигезендә, теркәү карточкаларында яки йорт кенәгәләрендә билгеләнгән үрнәктәге штамп белән гражданнарны хәрби исәпкә кую турында билге салалар.

Хәрби комиссариатларга гражданнарның, хәрби бурычка карата билгеләре булмаган очракта, әлеге документларны тиешле рәсмиләштерү өчен, хәрби исәпкә алу документларын һәм паспортларын тапшыралар.

Запастагы офицерларга һәм хәрби хезмәткә чакырылучыларга хәрби исәптән төшерү өчен тиешле хәрби комиссариатка шәхси килү кирәклеге турында хәбәр итәләр. Муниципаль берәмлектән читкә китүче хәрби хезмәткәрләренең хәрби комиссар карары белән мобилизация күрсәтмәләре алынырга мөмкин, бу хакта хәрби билетта тиешле тамга куела (хәрби билетларга алмашка бирелгән вакытлы таныклыкка). Хәрби-исәпкә алу мәгълүматларын төгәлләштерү кирәк булган очракта, аларга хәрби комиссариатларга шәхси килү кирәклеге турында хәбәр итәләр. Гражданнардан хәрби исәпкә алу документларын һәм паспортларны кабул итеп алганда расписка бирәләр.

Солдатның (матрос), сержантның (старшина), прапорщикның (мичман) хәрби билетында хәрби исәптән төшерү турында "Хәрби исәпкә алу һәм хәрби исәптән төшерү турында билгеләр" IX бүлегенең "Төшерелде" графасында җирле үзидарә органы штампы белән билге ясыйлар.

Запаста булуның иң чик яшенә җиткән гражданнарның яисә сәламәтлеге буенча хәрби хезмәттә яраксыз дип танылган гражданнарның беренчел исәпкә алу карточкаларының "Хәрби исәпкә алу һәм хәрби исәптән төшерү турында билге" IX бүлегенең тиешле графасында "яше буенча хәрби исәптән төшерелде" яисә "сәламәтлек торышы буенча хәрби исәптән төшерелде" дигән тамга ясыйлар.

Тамга хәрби комиссариатта ясалган язма нигезендә башкарыла:

запастагы офицерның хәрби билетында – 21 нче “Хәрби вазыйфаны үтәүдән азат итү турында билге" пунктында (32 нче бит);

солдат (матрос), сержант (старшина), прапорщикның (мичман) хәрби билетында - "X. Хәрби бурычны үтәүдән азат итү турында тамга" бүлегендә (26 нчы бит).

Хәрби комиссар карары буенча муниципаль районнан, авыл (шәһәр) җирлегеннән, шәһәр округыннан, федераль әһәмияттәге шәһәр эчендәге территорияләрдән яисә башка муниципаль берәмлектән читкә чыгып китүче гражданнан мобилизация предписаниесе алына, бу хакта хәрби билетта билге ясала.

Хәрби исәптән төшмичә, муниципаль берәмлектән яңа яшәү урынына чыгып киткән гражданнарның исемлекләрен төзиләр һәм ике атна эчендә аны хәрби комиссариатка тапшыралар.

Алынган мобилизация күрсәтмәләре белән бергә хәрби исәптән төшерелгән гражданнарның исемлеген төзиләр һәм ике атна эчендә хәрби комиссариатка тапшыралар.

Вафат булган гражданның хәрби исәпкә алу документында тиешле язма ясала, ул җирле үзидарә органы башлыгы имзасы һәм герблы мөһер белән раслана, шуннан соң хәрби билет (хәрби билет урынына бирелгән вакытлы таныклык) яки хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле граждан таныклыгы хәрби комиссариатка тапшырыла. Граждан хәле актларын теркәү органында яисә туганнарыннан вафат булган гражанның хәрби билетын (хәрби билет урынына бирелгән вакытлы таныклык) яисә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданның таныклыгын алу мөмкин булмавы турында хәрби комиссариатка хәбәр ителә.

Беренчел хәрби исәпкә алу документларында, шулай ук теркәү карточкаларында яки йорт кенәгәләрендә хәрби исәптән төшерү турында тиешле билге салырга.

Хәрби исәптән төшерелгән гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алу документларын хәрби комиссариатның исәп мәгълүматлары белән чираттагы чагыштыруга кадәр сакларга, шуннан соң аларны билгеләнгән тәртиптә юкка чыгарырга.

Ел саен, 1 февральгә кадәр, район хәрби комиссариатына алдагы елда беренчел хәрби исәпкә алуны алып бару нәтиҗәләре турында хисап тапшырырга.

**Чыбыклы авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе**
**таныштырылды «___»_____2021ел** **И.Н. Гадершин**

**Чыбыклы авыл җирлегенең**
**беренчел хәрби исәпкә алу белгече**
**таныштырылды «___»_____2021ел** ____________ **Е.А. Егорова**